ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2016 Казан ш. № 7-18/т

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге гомуми файдаланудагы җир өсте электр транспортында регуляр пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча даими пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү” турындагы 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ санлы, “Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы” 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ санлы Россия Федерациясе законнарына, “Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 1995 елның 7 мартындагы 239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына нигезләнеп, “Росия Федерациясендә автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр пассажир транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү” Федераль законын тормышка ашыру” турындагы 2015 елның 26 декабрендәге 107-ЗРТ санлы Татарстаны Республикасы законы белән, 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге гомуми файдаланудагы җир өсте электр транспортында регуляр пассажирлар ташу муниципаль маршрутлары буенча даими пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. “Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге гомуми файдаланудагы җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында” Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 19 сентябрендәге 7-19/т санлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип санарга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
25.11.2016 № 7-18/т
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
Түбән Кама шәһәрендә шәһәр элемтәсендәге гомуми файдаланудагы
җир өсте электр транспортында регуляр пассажирлар ташу
муниципаль маршрутлары буенча даими пассажирлар йөртүгә
һәм багаж ташуга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер тапкыр баруга һәм бер урынлы багаж ташуга максималь чик тарифлар (сумда) | | |
|---|---|---|---|
| | транспорт салонында билет алган чакта | юл йөргән өчен озак файдаланыштагы билет белән түләгәндә | |
| | | бер тапкыр барган өчен [1] | 50 һәм аннан күбрәк барган өчен [2] |
| Автобус | 22 | 20 | 15 |

<1> шәһәр элемтәсендә юл йөрү өчен билгеле бер сумма чикләрендә транспортта йөрү хокукы бирүче озак файдаланыштагы билет белән түләгәндә;

<2> шәһәр элемтәсендә юл йөрү өчен күрсәтелгән срок дәвамында билгеле бер санда транспортта йөрү хокукы бирүче озак файдаланыштагы билет белән түләгәндә.

Искәрмә: Багаж ташу бәясе бару бәясеннән аерым түләнелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге